Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Тогашево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

22 октябрь, 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Тогашево торак пунктында 2023 елның 22 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 102 (йөз ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 78 (җитмеш сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 71 (җитмеш бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 7 (җиде).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Сез, 2024 елда Тогашево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 80 яшькә җиткән гражданнарны, 1 төркем инвалидларны, көндезге уку формасы студентлары һәм мәктәп укучыларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:
   - авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
   - урам яктырту җайланмасын ясау» **кабул ителгән дип санарга.**
2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В. Поповская